РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ
КОШКИ-ШЕМЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘМӘК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

21 май 2025 ел №103-3

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Шәмәк авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, муниципаль норматив актны кануннарга туры китерү максатларында, Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 февралендәге 61-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Шәмәк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (15.02.2020 №75-2, 20.10.2020 №3-2, 23.11.2020 №5-1, 22.12.2020 №7-1, 22.06.2021 №23-4, 16.07.2021 №24-1, 02.02.2023 №66-2, 07.04.2023 №69-2, 08.06.2023 №72-1, 26.06.2023 №74-1, 25.03.2024 №83-1, 18.11.2024 №92-2, 18.04.2025 №99-2, 14.05.2025 №102-1 номерлы карарлары редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2 бүлектә 2.5 пунктта «Муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга,

1.2. 5 бүлектә:

а) 5.1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы - муниципаль берәмлек уставы нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органындагы вазыйфа, җирле үзидарә органының яисә муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән бурычлар даирәсе булган вазыйфа».

б) 5.5 пунктта «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 9 бүлектә:

а) 9.2 пункттанда «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.4. 18 бүлектә 18.8 пунктта «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында»сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5. 20 бүлекнең 20.2 пунктындагы «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен һәм «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.6. 22 бүлектә:

22.2 пункт:

а) 1 пунктның «в» пунктчасында, «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга.;

б) 2 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга.

в) 3 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, муниципаль хезмәт вазыйфасын үзе биләгән йә турыдан-туры аңа буйсынган яисә контрольдә тотылган җирле үзидарә органында ышанычлы яисә өченче затлар эшләре буенча вәкил булырга.»;

г) 4 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссияләрендә» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә» сүзләренә алмаштырырга.;

д) 5 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен һәм «сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 8 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең һәм аларның җитәкчеләренең» сүзләрен «һәм аның җитәкчесенең» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккач законлы көченә керә (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш (http://buinsk.tatarstan.ru).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Шәмәк авыл җирлеге башлыгы Никитина И.Н.